КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 18 июнь г.Казань № 479

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 927 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 927 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче, 2015 ел, 4 ноябрь, 835 нче, 2020 ел, 29 июнь, 540 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

өченче абзацта «психоневрологик интернатларда» сүзләрен «психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат-йортларда,» сүзләренә алмаштырырга;

таблица исеменең «Социаль хезмәтләр алучының Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү елыннан алдагы елның II кварталы йомгаклары буенча халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменә уртача исәпләнгән кереме күләме, %» графасында «социаль хезмәт күрсәтү елыннан алдагы елның II кварталы йомгаклары буенча,» сүзләрен «тиешле елга» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән карар белән расланган Социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы нигезендә социаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу тәртибенең 2 пунктының икенче абзацында «психоневрологик интернатларда» сүзләрен «психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат-йортларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның 1 пунктының  дүртенче абзацы  2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин